**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №229-46 «28» июль 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 октябрендәге 98-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Азнакай шәһәре прокуратурасының 2025 елның 30 июнендәге 02-08-02-2025/Прп531-25-20920040 номерлы протестын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 октябрендәге 98-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә ( 14.12.2022 №105-19, 18.04.2023 №116-21, 25.10.2023 №241-27, 14.12.2023 №160-26, 28.03.2024 №171-30, 29.08.2024 №187-34 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 статьяның 3 өлешендәге 9 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибен, составын һәм срокларын» сүзләренә алмаштырырга;

43 статьяның 2 пунктында:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана.»;

- өченче абзацта «1 апрельдә» сүзләрен «1 февральдә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 47 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет турында карар проектына бюджет ассигнованиеләрен муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бүлү турындагы карар белән расланган очракта, бюджет турында карар проектына муниципаль программаларның паспорты (паспорт проектлары) (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары) тапшырыла.»;

1.4. 52 статьяның 1 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибе, составы һәм сроклары һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.2 пунктының дүртенче абзацы 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин